| ГЛАВА ЗВЕЗДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЗВЕЗДА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20 сентябрь 2023 ел №11

Җирле үзидарә органнары муниципаль
хезмәткәренең коррупциягә каршы
тәртибе стандартына үзгәреш кертү турында
Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы авыл җирлеге

"Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Звезда авыл җирлеге башлыгының 17.12.2017 ел № 15 карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Звезда авыл җирлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәренең коррупциягә каршы тору тәртибе стандартына (05.06.2018 ел №13 редакциясендә) түбәндәге үзгәреш кертергә::

2. **2. 3.1 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә**:

«Муниципаль хезмәткәрләргә үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (тормыш иптәшенең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирмәү, әгәр мондый мәгълүматларны тапшыру мәҗбүри булса, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, алдан ук тулы булмаган мәгълүмат бирү яки дөрес булмаган мәгълүматлар муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.»

2. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Звезда авыл җирлеге башлыгы: М.В.Денисова